Проект

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Шәһәр Советы

КАРАР

«___» ___________ 2021 ел №

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлегенең 2020 елгы
бюджеты үтәлеше турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.5, 264.6 статьяларына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 81, 82 статьяларына туры китереп,

Шәһәр Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елгы бюджеты (алга таба – шәһәр бюджеты) үтәлеше турында хисапны 125 086 844,22 сум күләмендә шәһәр бюджетын финанслау чыганаклары белән, керемнәр буенча 10 153 683 963,61 сум күләмендә, чыгымнар буенча 10 028 597 119,39 сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча шәһәр бюджеты керемнәрен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) шәһәр бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча шәһәр бюджеты чыгымнарын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча шәһәр бюджеты чыгымнарын, 3 нче кушымтада каралганча;

4) бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча шәһәр бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын, 4 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яр Чаллы шәһәре
Хакиме Н.Г. Мәһдиев